Төркиләр һәм кытайлар бәйләнеше бердәмлекне дә, төрле каршылыкларны да үз эченә ала. Әлеге ике этник төркем арасындагы тарихи, мәдәни, иҗтимагый һәм тел аспектлары күпкырлы тикшеренү объектын тәшкил итә. Бу эзләнүләр әлеге халыкларның гасырлар буена мәдәни кыйммәтләр белән алмашуларын, сәүдә һәм үзара хезмәттәшлек итүләрен аңларга мөмкинлек бирә. Ә хәзерге лингвистик коммуникацияләр глобальләшү һәм миграция процесслары контекстында өйрәнелә. Тел бәйләнешләрен саклауда һәм үстерүдә мәгълүмат технологияләренең һәм социаль медиаларның роле безнең көннәрдә зур әһәмияткә ия була бара.

Иҗтимагый-икътисади аспектта тел багланышларының сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләргә йогынтысы карала. Телне һәм мәдәни үзенчәлекләрне белү төрки-татар һәм Кытай халыклары арасында эшлекле мөнәсәбәтләр һәм хезмәттәшлек үсешенә ярдәм итәргә дә, комачауларга да мөмкин.

Шулай итеп, тәкъдим ителә торган мәкалә төрки-татар һәм Кытай халыклары арасындагы лингвистик коммуникацияләр үзара баю һәм мәдәни алмашу тарихының бер өлешен чагылдыра. Бу процессларны тирәнтен аңлау һәм өйрәнү тарихи-мәдәни мирасны саклау өчен генә түгел, ә киләчәктә хезмәттәшлек итү формаларын үстерү һәм халыклар арасында дуслыкны ныгыту өчен дә мөһим булуын күрсәтә.

**Төп төшенчәләр:** төрки телләр, татар теле, кытай теле, тарих, лингвистик багланышлар, лексика

## Кереш

Төрки-татар һәм Кытай халыкларының лингвистик багланышлары тарихи лингвистиканың кызыклы һәм аз өйрәнелгән мәсьәләсенә карый. Гасырлар буена төрки-татар һәм Кытай халыклары сәүдә, мәдәни алмашу һәм миграция аша бер-берсе белән аралашып яшәгәннәр, бу аларның телләрендә һәм язма традицияләрендә шактый эз калдырган. Әлеге эшнең максаты халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрнең лингвистик эзләрен өйрәнүдән һәм анализлаудан, шулай ук хәзерге тел структуралары формалашуга ярдәм иткән үзара йогынтыларны ачыклаудан гыйбарәт.

Беренче чиратта, төрки-татар халыкларының һәм Кытай халкының борынгы заманга барып тоташкан тирән тарихи тамырлары булуын билгеләп үтәргә кирәк. Күп санлы халыклардан торган төркиләр Евразиянең мәдәни һәм сәяси үсешенә зур өлеш керткән. Икенче яктан, Кытай цивилизациясе – дөньяда иң борынгы һәм өзлексез мәдәни традицияләрнең берсе. Аларның үзара бәйләнеше ике мәдәнияттә, шул исәптән телләрдә дә тирән эз калдырган. Мондый бәйләнешләрне тикшерү ике телдә дә уникаль тел сыйфатларын формалаштыруга ярдәм иткән процессларга ачыклык кертергә мөмкин.

Тикшерү барышында лингвистик багланышларның төрле аспектлары: лексиканы үзләштерү, гомуми сүзлек фондларын формалаштыру һәм башка лингвистик феноменнар каралды. Бу багланышларның борынгы заманнардан алып бүгенге чорларга кадәрге тарихи хронологиясенә, шулай ук бу мәдәни һәм тел алмашулары барган географик маршрутларга аерым игътибар бирелде.

Мондый лингвистик бәйләнешләрнең башлангычын дөньяның төрле халыклары арасындагы үзара хезмәттәшлекнең төп каналына әверелгән Бөек Ефәк юлыннан эзләргә мөмкин.

Моннан тыш, борынгы лингвистик бәйләнешләрне өйрәнү хәзерге тел күренешләрен аңлау өчен зур әһәмияткә ия. Тарихи үзара тәэсир итешүләрне анализлап, хәзерге сүзләрнең һәм әйтелмәләрнең килеп чыгышын, шулай ук багланышларның телләргә сизелер-сизелмәс кенә булса да, тәэсирен яхшырак аңларга була.

Шулай итеп, әлеге эш төрки-татар һәм Кытай халыкларының лингвистик бәйләнешләрен һәрьяклап тикшерүгә һәм анализлауга юнәлтелгән, бу исә тарихи үткәнгә тирәнрәк кереп китәргә генә түгел, ә күп кенә хәзерге тел процессларына һәм күренешләренә аңлатма бирәчәк.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Бу хезмәттә сүз төрки-татар һәм Кытай халыкларының лингвистик багланышлары, аларга кагылышлы тарихи чорлар, телләрнең үзенчәлекләре турында барачак. Әлбәттә, әлеге телләрне капма-каршы куеп анализлауга багышланган эшләрнең саны күп түгел. Аерым алганда, теге яки бу телгә үтеп кергән сүзләргә багышланган мәкаләләр очратырга мөмкин, әмма тулы бер хезмәт, кызганычка каршы, әлегә күренми. Шуннан чыгып, бу эшне башкару вакытында алда искә алынган темалар, аерым төрки-татар һәм кытай телләренең төзелешенә караган материаллар кулланылды. Мисал өчен, Ә.Ш. Юсупова, Г.Ә. Нәбиуллина, Г.Р. Мөгътәсимова, Э.Н. Денмөхәммәтова, К.С. Фәтхуллова, Ф.Х. Җәүһәрова, А.Д. Батталова авторлыгында «Кытайда яшәүче татарлар» монографиясен [28] һәм Чинхен Шынг Маның «现代汉语语法» («Хәзерге кытай теленең грамматикасы») хезмәтен атап үтү урынлы булыр [1].

Безнең әлеге тикшеренү эше төрки-татар һәм кытай телләренең охшаш якларын анализлауга багышлануы белән аерылып тора. Хезмәтне башкарганда, күзәтү, чагыштырма-тарихи анализ, телләрнең структураларын типологик өйрәнү кебек метод һәм алымнарга таяндык, бу исә әлеге халыкларның телләрендәге гомуми сыйфатларны да, уникаль аспектларны да аерып күрсәтергә мөмкинлек бирде.

## Фикер алышу

Төркиләр – Евразиянең борынгы халыкларының берсе, аларны беренче тапкыр безнең эрага кадәр III гасырда ук искә алулары билгеле. Алар көнчыгыш Европадан Урта Азиягә кадәр киң территорияләрдә яшәгәннәр. Төрки кабиләләр һуннар, Төрки каганлык, Сәлҗүк династиясе һәм Госманлы империясе кебек бөек империяләрне формалаштыруда мөһим роль уйнаганнар [2, б. 36].

Кытай халкы – дөньяның иң борынгы һәм иң зур этник төркемнәренең берсе. Алар Кытай территориясендә борынгыдан бирле яши һәм династияләр, империяләр һәм мәдәни казанышлар белән бәйле бай тарихка ия. Кытай теле һәм язуы дөньяның иң борынгы тарихлы телләренең берсе булып санала.

Генеологик классификация буенча төрки телләр алтай телләре гаиләсенә карый [3, б. 224]. Ә кытай теле барлык диалектлары белән кытай-тибет телләре гаиләсенең кытай төркеменә керә [3, б. 229]. Шунысы игътибарга лаек: кайбер хезмәтләрдә кытай теленнән үсеп чыккан дип саналган япон һәм корея телләре алтай телләре гаиләсенә кертеп карала [3, б. 224]. Димәк, кытай һәм төрки телләр кардәш телләр түгел, генетик фондта бу ике телнең уртаклыгы юк. Әгәр төрки телләрдәге китаизмнарны лексик фонд яссылыгында карасак, алар төрле багланышлар нәтиҗәсендә кергән сүзләрне, ягъни контактлы фондны тәшкил итәләр.

*Алынма сүз* – халыклар арасында барган иҗтимагый-сәяси, мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә бер телдән икенче телгә үтеп кергән сүз. Алынма сүзләр барлык телләрдә дә бар, аларның үтеп керү юллары төрле булырга мөмкин [4, б. 96]. Билгеле булганча, төрки телләрдә гарәп-фарсы һәм рус-Европа алынмалары зур күпчелекне тәшкил итә. алардан тыш, һинд һәм кытай сүзләре (*алма, җиз, тәңре, сан, энҗе, түбән, хан, чәй, дию*) дә бар. Тел өлкәсендә эшләүче галимнәр аларны аерым бер телгә түгел, ә төрки телләр аерылмаган чорда ук кереп калган дип билгелиләр [5, б. 254]. Бу алынмалар гасырлар буе янәшә яшәп, сәүдә яки якын аралашу нәтиҗәсендә телгә үтеп кергәннәр.

Бу өлкәдә тикшеренүләр алып барган галимнәр (В.В. Радлов, С.В. Малов, Н.А. Баскаков, А.В. Дыбо) төрки телләрдәге кытай алынмалары әле өйрәнелеп бетмәгәнен ассызыклый. Шуның белән беррәттән, Кытай Халык Республикасында яшәүче уйгур телендәге кытай алынмаларына багышланган аерым хезмәтләр булуын әйтергә кирәк [6, 7, 8].

Сөйләм аша кергән алынма сүз телнең грамматик, фонетик закончалыкларына буйсына. Мәсәлән, 茶– *chá – чәй,* 珍珠– *zhēnzhū – энҗе.*

Язма чыганаклар аша кергән сүзләр, нигездә, үзгәрешсез саклана. Башка телгә кергән сүзләр тышкы яктан гына түгел, мәгънәсе ягыннан да төрле үзгәрешләр кичерергә мөмкин: мәгънәләре йә тарая, йә киресенчә, киңәя. Төшенчә атамасы буларак үтеп кергән алынма сүзнең мәгънәсе үзгәрми, әмма синоним рәвешендә алынган сүзнең мәгънәсе үзгәреш кичерә.

*Китаизмнарның* күпчелеге төрки телләргә рус теле яки Европа телләре аша кергән дип карала. Әмма болай фикер йөртү хата да булырга мөмкин, чөнки борынгы чор алынмалары борынгы төрки телгә турыдан-туры килеп кергән.

Әйтеп киткәнебезчә, кытай алынмаларының билгеле бер төркеме күпләп XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында актив кулланыла башлый. Алар башта Европа телләренә, аннан рус теле аша татар теленә дә үтеп кергәннәр. Рус телендә шактый үзләштерелеп, фонетик яктан җайлашып, төрки телләрнең лексик составын тәшкил итсәләр дә, бу сүзләр яңгырашы, лексик үзенчәлекләре белән аерылып тора. Фәндә алар неологизмнар буларак карала.

*Неологизмнар* – мәгънәсе яки сүз үзе аерым бер чорда яңа саналган пассив сүзлек составының бер берәмлеге. Сүзнең яңалыгы һәм пассивлыгы аерым бер тарихи чорга бәйле, төшенчәсе әһәмиятле, югалмый торган сүзләр соңрак актив лексикага күчеп, гомумкулланылыш сүзләренә әйләнәләр. Неологизмнарның дүрт төре бар:

1) *лексик* – башка телләрдән алынган сүзләр;

2) *лексик-семантик* – телдәге сүзләргә яңа мәгънә өстәлеп ясалган сүз;

3) *лексик-грамматик* – телнең үз морфологик чаралары ярдәмендә ясалган сүз;

4) *окказионализм* – язучылар, публицистлар, җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан стилистик максатларда ясалган сүз.

Телдә еш очрый торган китаизмнар беренче һәм икенче төрләргә карый. Аеруча икенче төрне аңлатып китү кирәктер. Мисал өчен, 馒头(mántou) – «мантый» сүзе. 馒头 (mántou) – кытай кухнясында чүпрәле камыр эченә ни дә булса салып, парда пешерелә торган кабартма [9, б. 122]. Хәзерге көндә бу ризык кытайча 包子 (bāozi) дип тә атала. *Мантый* билгеле бер чорда атамасы һәм пешерелү ысулы белән татарларга кереп калган. Төрки халыкларда аның берничә төре бар (иң киң таралганы – татарларныкы, үзбәкләрнеке һәм уйгурларныкы). Алар үзара охшаш, ләкин эчлегендә аермалар шактый. Мәсәлән, татар халкы мантый эченә ит (фарш), бәрәңге, суган сала; үзбәкләр – бәрәңге

урынына кабак, ә суган урынына еш кына әче сөт куша; уйгурларда исә мантыйның дүрт төре билгеле: 1) кабак белән сарык ите бертигез пропорциядә, 2) джусай (суганның бер төре) өстәп, 3) саргылт төскә кергәнче кыздырып, 4) джусайдан гына торган. Дөрес, хәзерге көндә «мантый» сүзе неологизм буларак каралмый, әмма аерым бер чорда ул яңа сүз булган.

Китаизмнарны үзләштерелгәнлек һәм үзләштермәгәнлек ягыннан карасак, алар үзләштерелмәгән лексиканың *экозтизмнар* төркеменә карый.

*Экзотизм/экзотик сүз* – аерым бер милләтнең, халыкның көнкүреш әйберләре, кием-салым, йола-гадәт атамалары. Алар, нигездә, алынмалар рәтендә кулланыла, һәм икенче телдә аларның эквивалентларын табып булмый. Чыннан да, соңгы елларда кулланылышка кергән кытай алынмалары нәкъ менә экзотизмнар дип карала. Чөнки бу сүзләр кытай мәдәниятендә генә кулланылып, аны таныткан сүзләр, һәм алар, күп очракта, предметларны атый. Мисал өчен, *эрху, феншуй, дао* һ.б. сүзләр.

Төрки телләрдәге кытай алынмалары борынгы төрки чорда ук керә башлаган. Аларны *биш тематик төркемгә* бүлеп карарга мөмкин:

1) титул, төрле профессия вәкиле, дәрәҗә атамалары:

*bek~beg* – бек, бәк, господин;

*tarxan* – салымнан ирекле ителгән дәрәҗә;

*tegin* – хан улы;

*xan* – хан;

2) рухи-мәдәни кыйммәтләрне гәүдәләндергән күренеш атамалары:

*bitik~bičik* – китап;

*burqan~burxan* – Будда;

*čyn~čin* – чын;

*küg~küj* – көй, җыр;

3) төрле матдә атамалары:

*altyn~altun* – алтын;

*čaj* – чәй;

*čojun* – чуен;

*suy~suw* – су;

4) көнкүрешнең төрле өлкәләренә караган предметлары атамалары:

*čan* – стакан;

*iš~is* – эш;

*paj* – өлеш, кисәк;

*qap* – капчык;

*taŋ* – таң;

5) билге һәм эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр:

*quw* – коры;

*tyŋ* – иң;

*tyŋla* – тыңла [6, б. 347-348].

Хронологик яктан бу алынмалар борынгы чорга да, аннан соңгы чорларга да карый. Әмма бик борынгылары, телгә кереп урнашу һәм актив кулланылу сәбәпле, хәзерге көндә алынма буларак кабул ителмиләр дә. Мисал итеп, түбәндәге сүзләрне китерергә мөмкин: *iš~is – эш, qap – капчык, quw – коры, suy~suw – су, taŋ – таң, teŋ – тигез, tyŋla – тыңларга* һ.б.

Төрки телләр, шул исәптән татар теле тарихи сәбәпләр һәм төп халкының географик урнашуы үзенчәлегенә бәйле рәвештә рус һәм Европа телләре йогынтысында төрле үзгәрешләр кичерә, бу телләр аша алынмалар белән дә даими баетылып тора. Шуңа күрә төрки телләргә рус һәм Европа телләреннән үтеп кергән китаизмнарны да карау урынлы булыр.

Макс Фасмерның «Этимологический словарь русского языка» хезмәтендә (1938–1950) кытай теленнән рус теленә кергән 8 сүз күрсәтелә [10, б. 239]. XX гасырда башланган сәяси, икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләрнең үсеше нәтиҗәсендә, хәзерге көндә бу төр алынмаларның саны шактый артты. Кытай теленнән инглиз, рус телләре аша төрки телләргә дә яңа сүзләр күчә.

Ә.Ш. Юсупова, Г.Ә. Нәбиуллина, Г.Р. Мөгътәсимова, Э.Н. Денмөхәммәтова, К.С. Фәтхуллова, Ф.Х. Җәүһәрова, А.Д. Батталованың «Кытайда яшәүче татарлар» монографиясендә (2014) Кытай татарлары телендәге кытай алынмалары турында болай дип язылган: «Кытай алынмалары, башка алынма берәмлекләр кебек үк, нигездә, исем, сыйфат сүз төркемнәренә караган лексик берәмлекләрне тәшкил итә. Әмма араларында фигыль сүз төркемнәренә караганнары да очрый. Алар тезмә фигыль буларак *кытай берәмлеге+кылу* татар ярдәмче сүзе ярдәмендә ясалалар һәм сөйләмдә актив файдаланылалар. Мәсәлән, *шы щан кылу – видеога төшерү; да йын кылу – өстәмә нөсхә ясау; фу йын кылу – копия ясау; җау шан кылу – фотога төшерү; шуака кылу – карта бирү; кайжи кылу – компьютер кабызу һ.б.*» [11, б. 192-193]. Димәк, кытай сүзләрен төрки телләр арасында уйгур телендә, шулай ук Кытайда яшәүче татарлар, казахлар, кыргызлар сөйләмендә күзәтә алабыз.

В.И. Новгородский «Китайские элементы в уйгурском языке» (1951) хезмәтендә

китаизмнарны түбәндәге тематик төркемчәләргә аерып карый (табл.1) [7, б. 83]:

Таблица 1.

| Тематика | Мисаллар |
|---|---|
| Хакимият оешмалары, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә караган, хәрби реалия атамалары | 中共– чжунгун – кытай компартиясе, 汉族– ханъцзу – кытай милләте,华侨– хуацяо – кытай эмигранты, 大学– дасюэ – университет, 京剧– цзинцзюй – театр, 团长– туаньчжан – полковник, 班长 – баньчжан – бүлек командиры |
| Азык-төлек һәм эчемлек атамалары | 豆腐 – доуфу – кузаклы сыр, 筷子 – куайцзы – таякчыклар, 饺子 – цзяоцзи – пилмән |
| Кием-салым атамасы | 旗袍 – ципао – күтәргән якалы хатын-кыз күлмәге |
| Предмет атамалары | 桌子– чжоцзы – өстәл,菜园子 – цайюаньцзы – бакча, 板凳 – банъдэн – такта,铡刀 – чжадао – зур пычак |

Югарыда күрсәтелгән сүзләр дә Кытай Халык Республикасында яшәүче халыкларның лексикасына бәйле рәвештә карала.

Кытай теленнән инглиз һәм рус телләре аша татар теленә үтеп кергән лексик берәмлекләрне түбәндәге таблицада күрергә мөмкин (табл.2) [7, б. 132]:

Таблица 2.

| № | Сүз | Кытайча язылышы | Кытайча әйтелеше | Аңлатма, тәрҗемә |
|---|---|---|---|---|
| **1.** | байховый (бөртекле чәй) | 百花 | bǎihuā | чәй төре |
| **2.** | дао | 道 | dào | юл, кагыйдә, дини агым |
| **3.** | женьшень | 人参 | rénshēn | дару үләне |
| **4.** | инь-ян | 阴阳 | yīnyáng | болыт-кояш |
| **5.** | кунгфу | 功夫 | gōngfū | хезмәт, остаз, көрәш төре |
| **6.** | мантый/манты | 馒头 | mántou | кытай кабартма-сы |
| **7.** | тайфун | 台风 | táifēng | циклон |
| | | | | атамасы |
| **8.** | улун | 乌龙 | wū lóng | чәй төре |
| **9.** | чәй | 茶 | chá | чәй, эчемлек |
| **10** | жемчуг / энҗе | 珍珠 | zhēnzhū | асылташ төре, энҗе |

Тикшеренү күрсәткәнчә, Кытай һәм төрки халыкларның телләрендә һәм, шулай ук, мәдәниятләрендә дә уртаклыклар шактый. Алар әлеге милләтләрнең ризыкларына һәм туклану традицияләрендә ачык күренә. Беренчедән, ризыкка карата мөнәсәбәтне билгеләргә кирәк. Төрки халыкларда көндәлек аралашуда якын кешеләрдән бер-берсенең эшләре турында белешкәч, ашауга кагылышлы сорау табигый күренә. Бигрәк тә бу олы һәм яшь буын арасындагы аралашуга кагыла. Әби-бабайлар, әти-әниләр һәрвакыт балаларыннан нәкъ менә шул хакта сорыйлар. Кытайларда исә *«Син ничек?», «Хәлләрең ничек?»* җөмләсенең конструкциясе исә турыдан-туры *«Син әле ашадыңмы?»* («你吃饭了吗?») *(пьинин – nī chīfàn le ma?)* дип тәрҗемә ителә [13].

Икенчедән, ризыкларның атамасына игътибар итсәк, бу милләтләрдә еш кына охшаш исемле, охшаш тышкы кыяфәтле, тәме охшаш аш-сулар очраганын күзәтә алабыз. Мәсәлән, Таҗикстанда, Казахстанда, Үзбәкстанда, Башкортстанда, Татарстанда билгеле булган **мантый** кытайларның 馒头 (пьинин – mán tou) белән бер үк. Бу очракта сүз охшаш исем генә түгел, хәтта тәме һәм пешерү ысулы турында бара. 馒头сүзен иероглифларын аерым карасак, ул «тулы баш», ягъни «төрле эчлекләр белән тутырылган баш формасындагы ризык» дигәнне аңлата ) [14, б. 21]. Төрки һәм Кытай халыкларында алар бертөрле формада, бердәй ысул белән, ягъни парда әзерләнә, тик бу ризыкларның эчлеге бераз аерыла. Төркиләрдә, гадәттә, ит, суган һәм бәрәңге кулланылса, кытайларда еш кына татлы (шәфталу (персик), сакура, роза кайнатмасы һ.б.), шулай ук тозлы (гөмбә, доуфу, кәбестә) эчлекле була. Аларда бу ризыкта ит һәм бәрәңге, гомумән, очрамый. Башка бик күп ризыклар бар, алар тышкы кыяфәте, исеме яки тулылыгы буенча охшаш.

Татар халкының **чәкчәге** – формасы һәм кулланылышы буенча охшаш ризыкларның берсе. Татарлар һәм башкортлар арасында аеруча популяр булган бу ризык күп майда кыздырыла да суыткannан соң бал белән бутап өелә. Татарларда бу ризыкның исеме өч төрле

аңлатыла. Беренчедән, ул «чык» формасында, шуңа күрә дә татар телендә «чык» сүзенә охшатып, «чәкчәк» дип аталган. Икенчедән, майда камыр кызганда чыккан тавыш белән охшаш дип әйтелә. Өченче аңлатма – «чәк» компоненты «кечкенә» сүзенең синонимы буларак кулланылган. Шуңа да чәкчәк вак камыр кисәкләреннән торганга, әлеге исем бирелгән. Р.Г. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә исә автор бу сүзнең килеп чыгышы турында болай ди: *Чәкчәк, чәкчәги, чәкчәки, чеп чәги* һ.б. > башкорт телендә сәксәк, сәксәгей «выпечка из скреплённых мёдом мелких круглых или подушкообразных кусочков теста, чакчак» > мари телендә чäкчäк id. < фарсыча чäкчäки «тамчылы ашамлык» ← чäкәчäк «тамчы-тамчы», чäкэ «тамчы». Шулай ук үзбәкчә чакчак «пестә чикләвеге», чәкчәк «катламлы торт». Затлы ашамлык төрләре татар телендә еш кына фарсы-таҗик даирәсеннән килә; чәкчәкнең «камырдан эшләнгән пестә» булуы да закончалыклы (чаг. Бавырсак, Бөйрәк)» [12, б. 269].

Кытай телендә моңа охшаган ризык 油条 (*пьинин – yóu tiáo)* исемен йөртә. Иероглифлары буенча ул «майда кыздырылган озынча предмет» дигәнне аңлата. Кытайда ул шулай ук сары төстә була. Әлбәттә, монда бал кулланылмый, һәм камыр кисәкләрен дә бер-берсенә беркетмиләр. Күпчелек очракта камырны төрле тәм өстәмәләре белән татландыралар, әмма аның тозлы вариациясе дә очрый. Төркиләрдә дә, Кытай халыкларында да бу ризык десерт булып санала [15, б. 91-92].

Тышкы кыяфәте һәм эчлеге белән охшаш башка ризыклар да бар. Мәсәлән, **долма.** Бу ризыкның исеме күп кенә төрки телләрдә «тутыру, тутырма, эчлек» (азәрбайҗан, төрек, төрекмән, үзбәк телләре) дип тәрҗемә ителә. Төрки халыкларда популяр булган долма кытайларда да очрый дип әйтсәк, хата булмас. Төркиләрдә бу ашамлык тапалган ит белән дөгене йөзем яфракларына төреп пешерелә. Шулай ук төрле тәмләткечләр, чикләвекләр кулланыла. Кытайда ул 春卷 (пьинин – chūn juǎn) дип атала. Әгәр иероглифлар буенча аерым карасак, «яз», «язгы», ә икенче өлеше «борылма», «борылырга» дигәнне аңлата [19, б. 4]. Кытайларның милли яз бәйрәме бар, аны үткәргәндә, билгеле бер ризыклар әзерләнә, 春卷 шуларның берсе. Аны еш кына шушы бәйрәмдә әзерлиләр, әмма гадәти көннәрдә дә урам кафеларында очратырга була. Дөге кәгазе эченә дөге яки токмач, тавык ите, фасоль, төрле тәмләткечләр тутыралар [17, б. 123].

Үзбәк халкының һәркемгә билгеле булган милли ризыгы **пылауны** да бу исемлектә карарга кирәк. М.Фасмерның этимологик сүзлегендә бу ризыкның исеме төрекчәдән «каты итеп пешерелгән дөге боткасы» дип бирелә [10, б. 698]. Үзбәкләрдә пылау дөге, ит, кишер, суган, төрле тәмләткечләр кулланып әзерләнә. Еш кына җиләк-җимеш өстәлә. Кытайларда исә бу ризык 炒饭 (пиньинь – chǎofàn) исемен йөртә. Иероглифларын өлешләп карасак – кыздырган (炒) дөге (饭) килеп чыга. Пылудан аермалы буларак, 炒饭га җиләк-җимеш, кишер, суган, тәмләткечләр салмыйлар. Дөгедән тыш, кытайлар бу ризыкка йомырка, күп кенә креветкалар яки дуңгыз ите өстиләр. Бу ризыкның тышкы кыяфәте, әзерләү процессы һәм ысулы шактый охшаш, тәмнәре дә бик нык аерылып тормый [18, б. 287].

Бу исемлеккә шулай ук **лагман** да керә. Лагман – бүген Урта Азия халыкларының милли ризыгы булып санала – үзенең тамырлары белән уйгур халкы тарихына барып тоташа. Нәкъ менә уйгурлардан ул кытайларга да, үзбәкләргә дә үтеп керә. Кытайда бу ризык ике исем йөртә – 拉面（пьинин – lāmiàn）, 拉面条 (пьинин – lāmiàn tiáo), ләкин алар бер үк «озын токмач» дигәнне аңлата [16, б. 173]. Үзбәкләргә исә аның исеме уйгур теленнән кергән дип санала. Ул шулай ук «тартылган камыр», «озын камыр» дип тә тәрҗемә ителә. Бу ризыклар тышкы кыяфәтләре буенча бик охшаш. Аерма шунда ки, үзбәкләрдә камыр ризыкларыннан тыш, ит, вак итеп туралган яшелчәләр, ә кытайларда эре итеп туралган яшелчәләр, балык, дуңгыз ите һәм йомырка була [20, б. 241–243].

Шулай итеп, Кытай һәм төрки халыкларның ризыкларындагы охшашлыкларны өйрәнү туклану традицияләренә тарих һәм географиянең тәэсирен күрергә мөмкинлек бирә. Кулланылган ингредиентлар һәм әзерләү ысуллары төрле булуга карамастан, ике төркем халыкның ризыкларында күп кенә уртаклыклар бар. Бу әлеге халыклар арасындагы гасырлар дәвамында тарихи алмашулар һәм үзара мәдәни бәйләнешләр йогынтысы белән аңлатыла ала. Бу охшашлыкларны аңлау кулинар дөнья турында белемнәрне киңәйтергә генә түгел, ә башка халыкларның мәдәни аермаларына һәм традицияләренә хөрмәт белән карарга да мөмкинлек бирә.

Алдагы мәгълүматлардан чыгып, төрки телләрендәге китаизмнарны берникадәр классификацияли алабыз:

- ✓ *Кытай сәнгатенә, диненә бәйле төшенчәләр туган телләрендәгечә атау:* дао, будда, кунгфу, ушу;
- ✓ *Кытай халык ризыклары*: мантый, чәй, улун, вок;
- ✓ *дару үләннәре исемнәре:* женьшень;
- ✓ *кием атамалары:* ханьфу, ципао;
- ✓ *тел гыйлеме төшенчәләре:* ханцзы, ханган, пьинин, путхунхуа һ.б.

Тарихи мәгълүматлардан чыгып, төрки телләргә китаизмнар үтеп кергән дүрт чорны аерып чыгарырга мөмкин:

**I чор** – безнең эраның VI йөз ахырына кадәрге вакыт аралыгы – *тыңла/тыңларга (听–tīng), су (水–shuǐ), чәй (茶– chá)* һ.б. Бу сүзләр төрки телләр лексикасына фонетик яктан яраклашып кереп урнашкан.

**II чор** – VII йөз–XIX гасыр башы – *мантый (馒头– mántou), женьшень (人参– rénshēn)* һ.б. Бу сүзләр сәүдәгәрлек юллары, яңа мәдәни кыйммәтләр, алмашыну белән килеп кергәннәр.

**III чор** – XIX гасыр башы–XX гасырның беренче яртысы – *тайфун (台风- táifēng), эрху (二胡– èrhú), дао (道– dào)* һ.б. Әлеге сүзләр глобальләшү процессының башы белән бәйле.

**IV чор** – XX йөз ахыры–XXI гасырлар – вок, феншуй, ханцзы, путхунхуа, ушу һ.б. Болар фәнни-икътисади багланышлар үсү сәбәпле, телебезгә башка телләр аша кергән алынмалар.

Кытай-төрки лексик параллельләрен өйрәнү бу телләр арасындагы тыгыз элемтәләрнең аларның лексиконына ничек тәэсир иткәнен күрергә мөмкинлек бирә. Тикшеренүнең мөһим нәтиҗәсе булып, Кытай һәм төрки телләр арасында сүз төзелешендә уртак тамырлар һәм охшашлыкларны ачыклау тора, алар халыклар арасындагы борынгы үзара бәйләнешләрне күрсәтә. Лексик параллельләр шулай ук халыкларның сүзләрне үзләштерү күренешләрен генә чагылдырып калмый, бәлки кытай һәм төрки халыклар арасында күп гасырлар дәвамында мәдәни, сәүдә һәм сәяси элемтәләр булуын да күрсәтә. Мондый параллельләрне өйрәнү телләрнең тарихи үсешен һәм аларның үзара бәйләнешен яхшырак аңларга ярдәм итә.

### Төп нәтиҗәләр

Әлеге эш барышында төрки-татар һәм Кытай халыклары арасындагы лингвистик багланышларны өйрәнүгә юнәлдерелгән тикшеренү эшләре үткәрелде. Башкарылган анализ мондый үзара бәйләнешнең тарихи контекстта да, хәзерге тел киңлегендә дә чагыла торган мөһим аспектларын һәм нәтиҗәләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Беренчедән, бу халыклар арасындагы лингвистик багланышларның тирән тарихи тамырлары булуы ачыклана, алар актив сәүдә һәм мәдәни алмашулар вакытында ук барлыкка килә. Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында күпер булып хезмәт иткән Бөек Ефәк юлы бу багланышларның барлыкка килүендә һәм үсешендә төп рольне уйный.

Икенчедән, алынмаларны һәм уртак (охшаш) лексиканы тикшерү төрки-татар телләрендә көнкүреш, технология һәм сәүдәнең төрле аспектларына бәйле Кытай сүзләре булуны күрсәтә. Шул ук вакытта Кытай теле дә төрки телләрнең йогынтысын кичерә, бу бигрәк тә Синьцзян һәм Үзәк Азия кебек интенсив үзара бәйләнеш барган өлкәләрдә күзәтелә.

Өченчедән, үзара тел баету процессында дини һәм мәдәни багланышлар зур роль уйнаган. Буддизмның, соңыннан исламның таралуы дини текстларны тәрҗемә итү белән бергә барган, бу шулай ук терминологияне алуга һәм яраклаштыруга ярдәм иткән. Бу уңайдан язуны җайлаштыру һәм куллану мәсьәләсе аеруча кызыклы, бу төрки-татар һәм Кытай язма традицияләрен баеткан.

Төрки-татар һәм Кытай халыклары арасындагы лингвистик багланышларның хәзерге этабы үзара хезмәттәшлекнең глобальләшү процесслары һәм мәгълүмати технологияләр үсеше белән тәэмин ителгән яңа формалары белән характерлана. Хәзерге вакытта эмиграция, сәүдә һәм мәдәни алмашулар телләрне өйрәнү һәм аларның үзара йогынтысын аңлау өчен шартлар тудыра.

Тел бәйләнешләрен анализлау төрки-татар һәм Кытай телләренең бер-берсеннән мәдәни, иҗтимагый һәм икътисади чынбарлыкны чагылдырган сүз һәм әйтелмәләрне алганлыгын күрсәтте. Мондый алынмалар лексиканы баетып кына калмый, халыклар арасындагы үзара аңлашуны да тирәнәйтә. Бу бәйләнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән интернационализмнар һәм калькалар сөйләм практикасында ныгып, әдәби һәм массакүләм текстларда чагылыш таба.

Заманча технологияләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тел алмашуын тизләтүдә һәм көчәйтүдә мөһим роль уйный. Интернет,

социаль челтәрләр һәм медиа яңа сүзләрнең һәм әйтелмәләрнең тиз таралуына ярдәм итә, шулай ук төрле мәдәният вәкилләре арасында актив аралашу һәм мәгълүмат алмашу өчен мәйданчыклар булдыруга ярдәм итә. Кытай фильмнары һәм музыкасы төрки-татар халыклары арасында аудитория таба, ә төрки мәдәният Кытайда популярлаша бара.

Йомгаклап әйткәндә, төрки-татар һәм Кытай халыклары арасындагы лингвистик бәйләнешләрне өйрәнү үзенчәлекле һәм әһәмиятле тарихи-мәдәни әһәмияткә ия булган фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәле юнәлеше булып тора. Бу бәйләнешләрнең закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен ачыклау мәдәниятара хезмәттәшлек динамикасын яхшырак аңларга мөмкинлек бирә һәм шулай ук ике халыкның тел һәм мәдәни мирасын саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм итә.

Тикшеренү эше ФПСП-2/24 темасы кысаларында башкарылды.

**Әдәбият**


1. 景恒生吗. 现代汉语语法 // Jǐnghéngshēng mǎ.Xxiàndài hànyǔ yǔfǎ. London: Routledge & Kegan Paul Archive. 2019. 425 p.
2. Зәкиев М.З. Татар халкы тарихы (этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге). Казан, 2008. 347 б.
3. Реформаторский А.А. Введение в языковедение/Под ред. В.А. Виноградова. М.: Аспект Пресс, 1996. 536 с.
4. Галиуллина Г.Р. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.
5. Гумилев Л.Н. «Древние тюрки». М.: Наука, 1935. 504 с.
6. Дыбо А.В. Лингвистичекские контакты ранних тюрков: Лексический фонд: пратюркский период. М.: Наука, 2006. 817 с.
7. Новгородский В.И. Китайские элементы в уйгурском языке. М.: Наука, 1951. 186 с.
8. Рахимов Т.Р. Китайские элементы в современном уйгурском языке. М.: Наука, 1970. 349 с.
9. Халимов Р. «Изначально имя «татар» носили племена, жившие на севере от Великой китайской стены…» [Электронный сайт]. URL: https://m.realnoevremya.ru/articles/66760-rafael-hakimov-o-kitae-v-tatarskoy istorii (дата обращения: 22.08.2024).
10. Фасмер М. Этимологический словарь русского языка (перевод с немецкого и дополнения члена-корреспондента АН СССР О.Н. Трубачева). М.: Прогресс, 1987. 832 с.
11. Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р., Денмөхәммәтова Э.Н., Фәтхуллова К.С., Җәүһәрова Ф.Х., Батталова А.Д. Кытайда яшәүче татарлар. Казан: Казан университеты нәшрияты, 2014. 383 б.
12. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М–Я). Этимологический словарь татарского языка: в двух томах. II том (М–Я). Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. 357 б.
13. Бюро китайских переводов С.К. Терентьева. [Электронный ресурс]. URL: http://chinese-russian.com (дата обращения: 27.08.2024).
14. Ван Чжицзы Лексико-семантическое поле «национальная кухня» в процессе обучения русскому языку иностранных учащихся // Язык, культура, менталитет: проблемы изучения в иностранной аудитории: материалы Международной научно-практической конференции 10-12 апреля 2003 года. СпБ: СПБУ, 2004. С. 20-22.
15. Ван Хэйянь. Русский перевод названий китайских блюд в аспекте транскультурной коммуникации // Вестник Калмыцкого университета, 2018. № 38 (2). С. 88-94.
16. 吴伟雄.好易学英汉笔译// Hǎo yì xué yīng hànbǐ yì. 广州:广东世界图书 出版公司, 2000. 342 页.
17. Чжан Мянь. Лингвокультурологические характеристики китайской национальной кухни // Успехи современной науки и образования. 2017. Т. 3. № 1. С. 122-124.
18. Москалева С. А. Особенности перевода названий китайских блюд // Восток и Запад глазами молодых ученых. Томск: Изд-во Томского университета, 2013. С. 285–290.
19. Yang X. Study on traslation of chinese food dishes // Open journal of modern linguistics. 2017. Vol. 7. № 1. P. 1-7.
20. Семенас А. Л. Лексикология современного китайского языка. М.: Наука, 1992. 279 с.

# ЛИНГВИСТИЧЕСКИЕ СВЯЗИ ТЮРКО-ТАТАРСКОГО И КИТАЙСКОГО НАРОДОВ

**Алиса Фаизовна Мухаметшина**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
alisafaizovna99@mail.ru.

**Раушания Сагдатзяновна Нурмухаметова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
rsagadat@yandex.ru.

Связь между тюрко-татарским и китайским народами имеет многовековую историю – начиная с древнейших времен, когда Великий Шелковый путь связывал Запад и Восток, создавая условия для обмена товарами, идеями, культурными ценностями, которые продолжаются и по сей день. Отношения тюрков и народа Китая включают в себя как единство, так и различные противоречия. Исторические, культурные, социальные и языковые аспекты взаимодействия этих двух этнических групп составляют многогранный объект исследования. Эти поиски позволяют понять, как эти народы веками обменивались культурными ценностями, торговали и взаимодействовали. Современные лингвистические коммуникации изучаются в контексте процессов глобализации и миграции. Роль информационных технологий и социальных сетей в сохранении и развитии языковых контактов приобретает в наши дни все большее значение. В социально-экономическом аспекте рассматривается влияние языковых контактов на торгово-экономические отношения. Знание языка и культурных особенностей может как способствовать, так и препятствовать развитию деловых отношений и сотрудничества между тюрко-татарским и китайским народами. Таким образом, предлагаемая статья отражает часть истории культурного обмена и лингвистической коммуникации между тюрко-татарским и китайским народами. Глубокое понимание и изучение этих процессов показывает, что они важны не только для сохранения историко-культурного наследия, но и для дальнейшего развития форм сотрудничества и укрепления дружбы между народами. Предлагаемая статья отражает часть истории взаимообогащения культурным обменом и языковым общением между тюрко-татарским и китайским народами

**Ключевые слова:** тюркские языки, татарский язык, китайский язык, история, лингвистические связи, лексика

Исследование выполнено в рамках темы ФПСП-2/24.